Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Советының бишенче чакырылышының бишенче утырышы

Пимәр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 декабрь, 2025 ел № 16

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Пимәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 38 номерлы карары (Советның 2023 елның 31 мартындагы 59 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 78 номерлы, 2024 елның 19 апрелендәге 86 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 100 номерлы, 2025 елның 24 ноябрендәге 8 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Пимәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 37.1 статьяның 3 пунктын «моңа күрсәтелгән чаралар Федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә караган һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынган очрак керми» сүзләрен өстәргә;

1.2. 37.1 статьяның 5 пунктында «Татарстан Республикасы законнары, Җирлек советы карарлары» сүзләрен өстәргә;

1.3. 37.2 статьяның 1 пунктының 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен шәхси счетлар ачу һәм алып бару, шулай ук муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр чыгымнары буенча операцияләр үткәрү һәм аларны санкцияләр белән тәэмин итү, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы - әлеге учреждениеләр тарафыннан җирлек бюджетыннан алынган акчалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов